КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 июль г.Казань № 552

2025 – 2027 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2025 - 2027 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру стратегиясен (алга таба - Стратегия) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль программаларны эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Стратегия нигезләмәләрен исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 ел, 04 февраль, 63 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 ел, 4 февраль, 63 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 16 декабрь, 1655 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин